АРБОР ТӨП БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ

# “Гаилә бәйрәме”

(әти-әниләр белән үткәрелгән бәйрәм)

Төзеде: Мифтахова Руфия Бильсур кызы,

2021

# Гаилә бәйрәме.

Зал бәйрәмчә бизәлә. Гаилә белән төшкән фотолар һәм рәсемнәр бәйгесенә стендлар.Китаплар күргәзмәсе оештырыла. Гаилә елының прототибы зурайтып эленә. Мәкаль-әйтемнәр, “канатлы сүзләр” язылган газеталар эленә.

“Бала – гаиләнең көзгесе: су тамчыларында кояш чагылган кебек, балаларда да ана һәм атаның әхлакый чисталыгы чагыла” (В.А. Сухомлинский)

I. Башлау

1а/б Хәерле көн, кадерле балалар, хөрмәтле әти-әниләр! Бүген без сезнең белән гаилә бәйрәменә җыелдык. (Укучыларның гаиләләре белән төшкән фотографияләрдән ясалган презентация кабызыла.) Гаилә- тормышыбызның нигезе, дәүләтебезнең киләчәге. Гаилә ул – олы сүз. Без гаиләдә үзебезне иң кирәкле, иң яраткан кеше итеп тоябыз. Әти-әни, әби-бабай гаиләдә иң хөрмәтле кешеләр. Тату гаиләдә яшәү- бәхет ул. Матур гаиләдә бер- береңне хөрмәтләп, бер-береңә ярдәм итеп яшәү- һәрберебезнең бурычы.

2 а.б. Кеше гомере аккан сулар кебек бик тиз узып китә.Аның ничек узуы һәркемнең үзенә бәйле. Мәктәп еллары да мәңгелек түгел. Балаларның да, сезнең дә гомергә исендә калсын дип, без бүген гаилә бәйрәменә җыелдык. Гаилә - ул җылы учак. Учак янына аның әгъзалары җыела. Гаилә никадәр нык булса, аннан килгән җылылык шулкадәр көчле була. Гаилә -тормыш нигезе. Ул нык, тату икән, димәк дәүләт тә, җәмгыять тә нык дигән сүз. Әти-әни аның тоткасы булса, балалар гаиләнең көзгесе. Әгәр тотка купмасын, көзге ватылмасын дисәң, бер-береңне санлап, рәнҗетмичә, хөрмәтләп яшәргә кирәк.

1алып баручы.
Бу кичәбез үтсен әле
Истә калып гомергә.
Балачаксыз яшәп булмый
Җирнең якты йөзендә.
Балачакның узганын
Сизмичә дә калабыз.
Күңелтулганминутларда
Сагыныпискәалабыз.
2алып баручы.
Бала – җаның,
Бала – уртак каның-
Буыннарга барыр киләчәк.
Бала – назың,
Бала – гүзәл язың,
Бала – ачылачак ут чәчәк.
Бала – бәгырь,
Бала - татлы сөенеч,
Бала – күтәрүче күкләргә,
Кулдан китсә, кайчак – кайгы-хәсрәт,
Күз яшьләре була күпләргә.
Бала – җылың,
Бала – йөрәк җырың,
Гасырларга барыр тавышы,
Бала, бала!
Барлык аналарның
Бәхете һәм... ачы язмышы.

Командалар арасында ярыш.

1а/б . Хәзер ике команда арасында ярышны башлыйбыз.

1. Хәзер әти-әниләргә иҗади эш бирәбез.Дәфтәр битенә шигырь язылган,ләкин төшеп калган сүзләр бар.

1командага

Эзе(калсын) керсез намусыңның  Көчлелегең б/н (горурланма)

Ни үтсәдә синең (кулыңнан)  (Кешелегең) б/н горурла!

2 командага  Син яшәмә(җирдә) файдасыз бер

Түмгәк(булып) тигез урында.

Янып калсын (гомерең)маяк булып,

Үзеңнән соң (килгән) буынга.

Хәрәкәтле уен. "Кер элү". Нәни йокыга китте. Хәзер әти -әниләргә бала чүпрәкләрен дә юып – эләргә була. Күзләр бәйләнә, сузылган бауга әни кеше керне элә бара, ә әти кеше каптыра.Җитезлек исәпкә алына.(Һәр командадан 1 пар чыга)

2. Кызыклы бирем.Сезгә бүген 3 яшь тулды. Әти-әниегез котлап, яңа уенчык машина бүләк итте. Әй, уйнадыгыз да соң инде! Безгә дә уйнап күрсәтегез әле (әтиләргә).

3. Муз.пауза. Җыр. 1 укучы җырлый.

4. Иҗади эш.Сөйдергәндә тел,биздергән дә тел ди халык.Матур,йомшак,иркәләү сүзләре бигрәк тә балаларга кирәк.Ул аны көненә 12 тапкыр тоярга тиеш. (һәр команда 12 сүз яза.1минутка)

1а/б.Матур сүз баланың кәефен күтәрә,тынычландыра ,эшчәнлеген арттыра.Шуңа күрә балалардан ягымлы сүзне кызганмагыз. "Җылы сүз җан азыгы", "Җылы сүз җанга рәхәт", - дип безнең халык белмичә генә әйтми шул. Әтиләр һәм әниләр бер-берегезгә нинди матур, назлы сүзләр әйтәсез икән? Әти һәм әни кешеләр чиратлашып ягымлы сүзләр әйтәләр

Ә хәзер балалар белән әти-әниләр нинди ягымлы сүзләр белән бер-берсенә эндәшәләр икән? Аларны тыңлыйк.Балалар белән әти-әниләр әйтешәләр.

Бик матур сүзләр генә әйтешеп яшисез икән.

5. Хәрәкәтле уен. Чаңгы шуу (1 чаңгыда бер гаилә)

6. Кызыклы бирем.1 ком. Бишектә бәби елый. Һич туктамый. Әти кеше берәр җаен тап, зинһар өчен. (Әни-бала, әти-әти ролендә)

2 ком. Иртә белән балагызны балалар бакчасына озату күренешен күрсәтегез.(Балалар киреләнә) (Әни-бала, әти-әти ролендә)

7. Муз.пауза. Җыр. 1 укучы җырлый.

8. Иҗади эш.Ә хәзер татар халкының милли ашлары буенча ярыш оештырып алыйк әле.

1 командага:

- Эченә бәрәңге яки тары ярмасыннан эчлек салып пешерелгән ашамлык (кыстыбый).
- Бик үзенчәлекле ашамлык. Эчлеге рәт –рәт итеп тезелә. (гөбәдия)
- Күркәм ризык, туй мәҗлесенең бизәге (чәк-чәк).

2 командага:

- 2 сүздән тора. Татар халкының милли ризыгына керә (кош теле).

- Көн саен кулланыла торган ризык. Аннан башка ашау үтми. Аңа халык дан җырлый (икмәк).

- Аш пешергәндә кулланыла. Татар халкына хас ризык (өй токмачы).

9. Хәрәкәтле уен: Бау тартыш

10. Кызыклы бирем.Элек бит инде Балаларны тапмыйча, кызмы, малаймы икәнен белми идек. Үзегез беләсез инде, ул вакытта сотовыйлар юк, хатыннар больницада 3 нче катта ята. Бер-береңне ишетмисең, ымлыклар б-н генә сөйләшергә туры килә. Сез дә менә шул чор ир-атларын сурәтләргә тиеш буласыз инде.

Больницагакилдегез, сөйләшәсез:

-Хәлең ничек?

-Көчкә котылдым

-Кызмы? Малаймы?

Күрсәтә: кыз яки малай

-Кемгә охшаган?

-Кемгә охшаганын күрсәтә?

-Кайчан чыгасың?

-4 көннән чыгам

-Нәрсәләр алып килергә?

-Хатын үзе күрсәтә

-Мин сине бик яратам, мин сине бик сагындым

Мин дә сине бик яратам, мин дә сине бик сагындым.

11. Муз.пауза. Җыр. 1 укучы җырлый.

Балаларны озату. Бәйрәмне табын артында дәвам итү.

Мәҗлесне ачу.

Нинди гүзәл бәйрәм бүген
Мәҗлесне ачып, тост күтәрик
Шатлык ташый күңелдә.
Гадәт бит ул һәрбер табында.
Бөтен бәхет шушы өйгә
Әйдә, дуслар, тост күтәрик әле
Гүзәл туташ, чибәр ханым, синдә
Моң һәм назның һич юк исәбе.
Сыяр иде йомшак күңелеңә
Ятим дөньяның бер кисәге.

Тулган кебек күренә.
Шушы очрашу хакына.
Без бит дуслар сирәк очрашабыз
Ягез, бокалларны күтәрик.
Бергә җыелганда матур итеп,
Онытылмаслык итеп утырыйк.

6. Ханымнарга

Назларыңа күмәсең тирәңне
Кулларыңнан гөлләр түгелә.
Утыртасы иде үзеңне дә
Дөнья җәннәтенең түренә.

Юк, бер көнгә түгел, гомерлеккә.
Нәфис кулларыңа гөл биреп.
Исерергә тыңлап моңнарыңны,
Сокланырга буй - сының күреп.
И, нәфис зат, серле сандык кебек
Кемнәрне син әсир итмәдең
Үзең өчен генә яшәмәдең,
Хезмәт тирмәсеннән китмәдең
Табигатең белән әзер булдың
Үз-үзеңне корбан итәргә.
Тик бәхетле булсын газизләрең -
Гомерең буе әзер көтәргә.

Аек акыл белән эш итәсең,
Сабырлык тажыдыр башыңда.

Бәйрәм итик әле бер шаулатып,
Онытып торыйк бүген барсын да
Кояш көлмәс,
Корыч эремәс ялкынсыз.
Ирне утлы ялкыннарда яндырып,
Кол иткән дә,
Гөл иткән дә хатын кыз.

Хатын-кызлар табыннарның бизәге,
Җирдә булган бөтен ямьнең үзәге.
Илләрне да бар иткән һәм зур иткән.
Хатын-кызнын барчасы җир гүзәле.
Хатын-кыз-ул нур чәчкәседәй сабый,
Назлы иркә, баллардин татлы җаный.
Ул-иң газиз күз нурыбыз, пакь ана.
Бар гүзәллек аналардан башлана

9. “Әйе, юк”. Әниләр өчен бирем Тиз генә җавап бирергә.

- Ашаралдыннанкулларныюарга кирәк. (Әйе)
- Җәйартыннан кыш килә.(Юк)
- Куянныңколакларыкыска, койрыгыозын. (Юк)
- Китап- кешенең дусты.(Әйе)
- Татарларикекуллаписәнләшәләр. (Әйе)
- Әтәчйомырка сала. (Юк)
- Боз кардан тизрәкэри. (Юк)

10 . Әтиләрнең зирәклеген сыныйк әле.

1). Ул бөтен өйдә дә бар. Аның белән әтиләр эшли. Кайчагында әниләр кулына да эләгә. Шаян малайлар кулына да эләккәли. Ул чагында бу корал кадакка түгел, бармакка төшә. ( чүкеч)

2). Аны йомырка белән балдан ясыйлар. Аның бик ваклары, бармак хәтлеләре дә була. Үзе бик тәмле, авызда эри. Кунак каршылаганда ипи-тоз белән бергә йөри. Исемедәбикматур. Ике өлештән торса да, бертөслеәйтелә. (чәк-чәк)

3). Ултөпаралашучарасына әйләнеп бара. Анысөйләшәбеләторганһәркемкуллана. Өйнеке дә, кесәнекедәбула. Улбулмаганберөйдәюк. Хәттаәбиләркулында да күрергәбула, чөнкибалалархәленбелергәкирәк. (телефон)

4). Аныбөтенкешедәярата, чөнкиул – төп ял итү җиһазы. Аеручаәтиләр. Арыпэштәнкайтканнансоң, аңаутырыпрәхәтләнеп телевизор карыйлар. Аның чүпрәктән дә, күннәндәэшләнгәннәребула. (диван)

5). Ул - татар халкыныңмиллиашамлыгы. Кунакларкилгәндәпешерелә. Түгәрәкбула, мичтә яки духовкада пешә. Эчендәтәмлеәйберләребула: йөзем, дөге, җимеш... (бәлеш, гөбәдия)

6). Уләтиләрнеңяратканәйберсе. Кайчагындааныңэчендәэниләрне дә күрергә мөмкин. Ләкин йөртә белмәсәң, кирәкледокументыңбулмаса, аңаутырыргаярамый. Хокуксаклаучылар да анытуктатыргабикярата. (машина)

7). Аныбарлыккешедәярата. Улбердәискерми, геляңара. Арганчакта ял иттерә. Нәнибалаларныйоклатканда да кирәк. Улелата да, моңландыра да, күңелне дә күтәрә. (җыр)

- Молодцы, этиләр! Сынатмадыгыз!

3 . Уен. Хәзер <u>“Иң оста биюче” дигән (“Самый лучший танцовщик”) уен уйнап алырбыз.</u> Бу уенны уйнар өчен миңа 5 кеше кирәк булачак. Уенның шарты мондый:

- 1). Татарча биергә.
- 2) Аяклар белән генә биергә, кулларны селкетмәскә, кем кулын селкетә, уеннан чыга.
- 3) Куллар белән генә биергә. Башка җирне селкетергә ярамый. Әгәр бу шарт үтәлмәсә, уеннан чыгарга туры киләчәк.
- 4) Гәүдәне, аяк—кулларны селкетмичә баш белән генә биергә.
- 5) Күз һәм авыз белән генә биергә.
- 6) Авыз беләнгенәбиергә.
- 4. “Иң оста биюче” (“Самый лучщий танцовщик”) дигән медаль тапшырыла.
- 5. Бозэретү—“Иңкайнаркеше”—“Самый темпераментный, горячий человек”
- 6. Лимон ашау—“Иңсабыркеше”—“Самый терпеливый человек”
- 8. Җыр.

<u>Тәнәфескә чыгу. Уеннар уйнау</u>